КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 апрель г.Казань № 316

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, 628 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, 628 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 02 июнь, 331 нче, 2018 ел, 25 гыйнвар, 40 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хакимияте органнарыннан алынган белешмәләр, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы турында» 2010 елның 8 сентябрендәге 697 номерлы карары нигезендә ведомствоара электрон бәйләнешнең бердәм системасы аша һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәткәндә һәм дәүләт функцияләрен үтәгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибе турында» 2012 ел, 07 август, 674 нче карары нигезендә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системасы аша алынган белешмәләр;

кабул итү-тапшыру актлары,шартнамәләр, килешүләр, контрактлар;»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Исәпкә алу объекты реестрына кертү яки Исәпкә алу реестры объекты турында белешмәләр составына үзгәрешләр кертү өчен, дәүләт милкенең төрле хокукларына ия булган юридик зат (алга таба – Мөрәҗәгать итүче), әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы Электрон документлар әйләнешенең ярдәм ведомствоара системасы ярдәмендә яисә кәгазьдә озату хаты белән (гаризаны Татарстан Республикасы электрон документ әйләнешенең ярдәм ведомствоара системасы аша җибәрергә мөмкинлек булмаганда) Министрлыкка гариза (алга таба – гариза) бирә.

Кәгазьдә җибәрелгән очракта гариза түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

юридик затның исеме кыскартылмый, текст ачык язылган, гаризада төзәтүләр юк;

гариза битләренә сан сугылган, алар тегелгән, мөһер белән беркетелгән (булган очракта);

гаризада аның эчтәлеген бертөсле аңлатырга мөмкинлек бирми торган бозулар яисә төзәтүләр, сызылган сүзләр һәм башка төзәтмәләр юк.

Әгәр Мөрәҗәгать итүче дәүләт унитар предприятиесе булса, гариза белән вәкаләтле орган теркәгән уставның актуаль версиясенең күчермәсе өстәмә рәвештә җибәрелә.

Бер үк вакытта гариза Мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле заты тарафыннан электрон формада махсус программа продукты ярдәмендә җибәрелә һәм үз эченә ала:

Реестрга мәгълүматлар кертелә торган объектлар исемлеге;

Реестрга мәгълүмат кертү өчен нигез булып торучы документның скан-күчермәсе (объектлар исемлеге күчемсез милек объектларын үз эченә алган очракта).

Махсус программа продукты аша электрон рәвештә тапшырыла торган объектлар исемлеге турындагы белешмәләр Татарстан Республикасы электрон документ әйләнешенең ярдәм ведомствоара системасы аша яисә кәгазьдә җибәрелә торган мәгълүматларга тәңгәл булырга тиеш.»;

2.3.1 һәм 2.3.2 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

2.4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бирелгән гаризаның әлеге Нигезләмәнең 2.3 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;»;

алтынчы абзацта «30 көнлек срокта бирергә тиеш» сүзләрен «30 көнлек срокта җибәрә»сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бирелгән гариза әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килми;

Мөрәҗәгать итүчегә, сәбәпләрен күрсәтеп, Реестрга мәгълүматларны кертү мөмкин булмавы турында махсус программа продукты аша хәбәр ителә.»;

әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән);

әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасын үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән);

әлеге Нигезләмәнең 5 нче кушымтасының искәрмәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ведомствоара электрон хезмәттәшлек бердәм системасы турында» 2010 елның 8 сентябрендәге 697 номерлы карары нигезендә Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы аша яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәткәндә һәм дәүләт функцияләрен башкарганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибе» 2012 ел, 07 август, 674 нче карары нигезендә ведомствоара электрон бәйләнешнең төбәк системасы аша бирелә торган өземтә башкаручының электрон имзасы белән раслана.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин